Хезмәт торак урынына наем шартнамәсе буенча гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында " 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарга торак урыннарын хезмәт торак урынына наем шартнамәсе буенча бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.
2. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 31.10.2022 № 697 карарын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**